**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлегенең Бушанча торак пунктында**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«20» октябрь, 2019 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлегенең Бушанча торак пунктындагражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз)сумм күләмендә алып барырга.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

.*а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:*

- урамдагы яктырткычларны ремонтлау,моның өчен материаллар сатып алу
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы тиешле һәм тиеш булмаган чүплекләр территорияләрен чистарту;

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Олы Урсак авыл җирлеге Башлыгы Г.А.Зиннәтуллин

Совет Большерусаковского сельского поселения
Олы Урсак авыл җирлеге Советы
ИНН 1621000478